ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

"Концессия килешүләре турында" Федераль законның 40 статьясына үзгәреш кертү хакында" федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. "Концессия килешүләре турында" Федераль законның 40 статьясына үзгәреш кертү хакында" федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә.

2. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына, шулай ук Татарстан Республикасыннан сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасын хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.

3. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында күрсәтелгән федераль закон проектын караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми вәкиле итеп Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Фәйзуллин Ирек Әнвәр улын билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2018 елның 19 ноябре
№ 2593-V ДС